**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**КАРАТУН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

# КАРАРЫ

2022 ел, 2 июнь № 89

**Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Каратун авыл җирлегенең Генераль планына үзгәрешләр кертү турында**

«Россия Федерациясе Су Кодексына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 1 маендагы 122-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Каратун авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Каратун авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Каратун авыл җирлегенең генераль планын раслау турында» 2020 елның 17 февралендәге 237 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Каратун авыл җирлеге советының Генераль планына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 3 нче таблицаның 3.5.1 нче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«туфракның уңдырышлылыгын арттыру максатларында агып төшүче сулардан файдалану;».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) һәм җирлекнең мәгълүмат стендларында игълан итәргә (бастырып чыгарырга).

3.Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Каратун авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

**Каратун авыл җирлеге**
**Башлыгы** **Р.С. Исмәгыйлев**